**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БОЛЬШЕШЕМЯКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ШӘМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 56-6-48, факс 56-6-48

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**27 .10. 2025** **№ 3**

**2026 елда гражданнарга үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлегенең Кече Бисәр торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Олы Шәмәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәкә авыл җирлегенең Кече Бисәр торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 13 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәкә авыл җирлегенең Кече Бисәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итәргә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?; махсус хәрби операциядә катнашучыларның (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) һәм аларның гаилә әгъзаларының, атап әйткәндә: ата-аналарның, ир белән хатынның, балигъ булган балаларның; гаилә әгъзаларының, атап әйткәндә: махсус хәрби операциядә һәлак булган катнашучыларның (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) ата-аналарының, ирләренең һәм хатыннарының, балигъ булган балаларының (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр); ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнарның һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә акчалар:

- торак пункт чикләрендә (Кече Бисәр авылы, Городская ур., Свердлов ур. буенча) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотумы?)».

» КАРШЫ «РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Шәмәк авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Шәмәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка

җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **А.И. Афанасьев**